Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

Сигезенче сан

Апрель, 2016 нчы ел




***Габдулла Тукайга багышланган махсус сан***

**Гимназиядә Габдулла Тукай-ның 130 еллыгына башланган ункөнлек бара.**

Бердәм Тукай дәресләре

Күргәзмә «Рәсемнәрдә - Тукай геройлары»

Викторина «Син Тукайны беләсең-ме?»

Әдәби-музыкаль кичә “Йөрәкләр-дә син, Тукай”

Конкурс «Сәнгать-ле сөйләм оста-сы”

Әдәби бәйге “XXI гасыр Шүрәлесе белән үткән бер көн”

Ирекле микрофон “Тукай чәйхәне-се”

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ



### Утырып уйлар уйладым

Гимназиябезнең алыштыргысыз китапханәчесе Солтанова Гөлшат Марс кызы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы үткәргән Туфан Миңнуллин исемендәге укытучыларның һәм укучыларның III республика конференциясендә "Утырып уйлар уйладым" лауреат исемен яулады. Гөлшат Марсовнаны гимназия администрациясе һәм укытучылары исеменнән котлыйбыз һәм киләчәктә дә зур уңышлар теләп калабыз!




### Компьютерны иярләүчеләр бәйгесе

Түбән Кама шәһәрендә "Компьютерны иң яхшы белүче" исеме астында Татарстан Республикасы турниры узды. Безнең районны әлеге турнирда составында 9 нчы сыйныф укучылары Гыйлемов Азат, Галиев Илназ, Муллагалиева Алсудан торган команда яклады. “Электрон газета” номинациясендә команда икенче урын яулады. Команда җитәкчесе – А.Р.Кадирова.



### Германиядән кунак

Гимназиябезнең 10-11 нче сыйныф укучылары Германиянең Регенсбург шәһәреннән килгән студент кыз – Клаудиа һәм 2014 нче елгы чыгарылыш укучысы Эльза Гиздатова белән очраштылар. Алар икесе дә уртак программада катнашалар, фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнәләр. Укучылар үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап алдылар, Германиядә үз яшьтәшләренең тормышы белән кызыксындылар.



### Баскетбол

Гимназиянең кызлар җыелма командасы РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы оештырган Россиякүләм Спартакиада кысаларында баскетбол буенча регионара ярышларда икенче урынга лаек булды. Команда җитәкчесе - физик тәрбия укытучысы Д.Г.Шәйхетдинов.



### Олы йөрәкле егет

9а сыйныфы укучысы Ринат Сафиуллин белән күпләр таныш. Аның исеме, спортның татарча көрәш төре буенча күпсанлы республикакүләм ярышлары җиңүчесе буларак, гимназиянең “Рекордлар китабы” на кертелде. Ринат Сафиуллин – игелек иясе. Милли көрәш буенча соңгы ярышта алган премиясен ул Мари Бүләр авылында янгын вакытында йортсыз калган күп балалы гаиләгә тапшырды. Афәрин, Ринат! Синең кебек асыл егетләр күбрәк булын иде!

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

# РЕДАКТОР МӨНБӘРЕ




Тукай иҗаты җиһанга ямь, яктылык, яшәү көче бөркеп, күңелләрне җылытып торучы мәңгелек кояш кебек бер көчкә ия. Ничәмә-ничә буын балалары Габдулла Тукайның Шүрәле, Су анасы геройларыннан сабак алып яши. Өлкәннәр Тукайның сатирик әсәрләре йогынтысында үз тормышына бәя бирә, лирик шигырьләре аша күңелен дәвалый, фәлсәфи әсәрләре аша дөньяга карашын формалаштыра. Заман тудырган һәм милләтне борчыган бик күп сорауларга җавапларны Тукай иҗатында табарга мөмкин.

Айлар-еллар, көннәр-төннәр, искән җилләр рәвешенә кереп, табигый Вакыт ага да ага. Габдулла Тукай белән бергә атлаган чорыбыз да инде 130 ел! Тукай – бары 27 ел яшәп, фани дөньядан бакыйлыкка күчеп киткән кеше. Иҗат өчен Тукайга нибары сигез генә ел бирелгән булып чыкты. Табигый һәм иҗтимагый Вакыт агышында бу бер мизгел генә. Ләкин зур талантларның гомер озынлыгы еллар белән түгел, бәлки нинди әдәби мирас калдыруы белән бәяләнә. Без шагыйрь яшәгән еллардан ераклашкан саен, аның иҗатының бөеклеге, асыл мәгънәсе тагын да куәтлерәк һәм тирәнрәк ачыла бара. Тукай бүген дә әдәбиятыбызның алгы сафында баруын дәвам итә.Тукай мирасы – бәһаләп бетергесез рухи хәзинә. Җирдәге гомеренең кыска булачагын пәйгамбәрләрчә сизенгәндәй, Тукай алтынга торырлык вакытын юкбарга әрәм итми: иҗатында халык мәнфәгатьләрен, милли әхлак кануннарын, телне саклау ихтыяҗын калку итеп куя. Мин аны татар әдәбиятын дөнья киңлегенә алып чыккан милли шагыйрь дип атар идем.

Тукай өчен шагыйрьлек ул – яну-көю, гаделлек, хаклык өчен көрәш, теләсә нинди шартларда вөҗданыңа, намусыңа тугры калу дигән сүз. Тукай өчен шигърият – яшәешнең төп рәвеш-формасы, асыл максаты.

Тукай иҗаты – татар халкының йөз аклыгы ул. Нинди темага гына язмасын, ул аларга татар күзе, татар менталитеты аркылы якын килгән. Мондый шагыйрьне булган милләт – зур һәм талантлы милләт, үткәне һәм киләчәге булган милләт. Без үзебезне шушы милләтнең кечкенә бер кисәге итеп саныйбыз, туган җиргә, халкыбызга, милләткә хезмәт итү – безнең өчен зур горурлык. Татар милләтен, милләтнең асылын, татар телен саклыйм дисәң, Тукай рухын, Тукай мирасын сакларга кирәк! Табигый Вакыт агышында Җирдә матур эшләребез белән Милләтебез киләчәгенә исемебезне язып калдырырга тырышып яшик, кадерле яшь дуслар!

***Эльмира Тимергалиева***

### ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ТУРЫНДА КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРНЕҢ ФИКЕРЛӘРЕ

***Фатих Әмирхан:***

*...Аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды... Шәхси тормыштан мәхрүм Тукаев үзенең шигырьләре, ул шигырьләрнең халык күңелендә яңгыраткан яңгырашы белән генә яшәде, шул гына аңа тормыш иде.*

*****

***Гали Халит:***

*Тукай – хәтта һәр авазның ритмик һәм музыкаль бирәмлеген сизеп, үлчәп иҗат иткән шагыйрьләрнең иң күренеклесе.*

*****

***Нәкый Исәнбәт:***

*Тукай турында сөйләгәндә, аны Пушкин белән чагыштырырга һәм аны татарның Пушкины дип атарга яраталар. Турыдан-туры мәгънәдә булмаса, бу чыннан да шулай. Чөнки Пушкин рус поэзиясенә нигез салса, Тукай татарның яңа шигърияген тудыра.*

*****

***Фәрит Мөхәммәтшин:***

*Бөек татар шагыйре, искиткеч талант иясе Габдулла Тукайның исеме көннән-көн киңрәк яңгыраш ала. Ул, бөтен төрки халыкларның уртак шагыйренә әверелеп, күптән инде дөньякүләм танылу тапты. Г.Тукайның тирән фәлсәфә һәм халкына, туган җиренә чиксез мәхәббәт, гуманизмның якты идеяләре белән сугарылган шигърияте гомумкешелек байлыгына әверелде.*

*Халкыбызның горурлыгы булган Тукай иҗаты бүген дә үзенең шифалы йогынтысын дәвам итә; аның әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителде. Г.Тукайның Идел буе халыклары телләренә тәрҗемә ителгән шигырьләре тупланган әлеге җыентык шагыйрь тарафыннан күтәрелгән милләт һәм дәүләтләр язмышы, милли мәдәният һәм тел, халыклар тигезлеге, гореф-гадәтләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләренең бүген дә никадәр актуаль булуын тагын бер кат раслый.*

# ТАЛАНТЛЫ ЯКТАШЛАРЫМА КҮҢЕЛЕМДӘ һӘЙКӘЛ КУЯМ...

***Мөслим төбәге - күренекле шәхесләргә, талантларга бик бай төбәк. Алар иҗаты белән таныш булу – зыялылык билгесе. Яраткан язучыларга "Хыялдагы һәйкәл" проекты өстендә эшләдек. Теманы өйрәнү барышында без үз асылыбызга кайткандай булдык, киләчәгебез турында матур уйлар туды, күңелләрне шулкадәр талантлар биргән Мөслим төбәге өчен горурлык хисләре биләп алды. Әлеге байлыкны башкаларга да җиткерүне үзебезнең бурычыбыз дип саныйбыз.***

***Проектта 10 нчы сыйныф укучылары катнашты.***

***Түбәндәге сораулар тәкъдим ителде:***

***Сез кайсы әдипкә һәйкәл куярга уйлыйсыз?***

***һәйкәл кайда булырга тиеш?***

***һәйкәл өчен нинди материал кулай булыр иде?***

***Әдипне нинди кыяфәттә итеп күзаллыйсыз?***

***һәйкәлгә нинди сүзләр язылган булырга тиеш?***

Тукай исемендәге дәүләт премиясенә 2016 нчы елда дәгъва итүче якташыбыз Шәмсия Җиһангировага багышланган проектны тәкъдим итәбез.



Шәмсия Гатуф кызы Җиһангирова (Гарипова) 1951 елның 28 февралендә Татарстанның Мөслим районы Баек авылында туа.

Шәмсия Җиһангирова — җырчы шагыйрә. Аның шигырьләре табигый агышлы, җырлап тора. Мөгаен, шуңа күрәдер дә композиторларыбыз аның иҗатына аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Җырлары камил эшләнешләре белән генә түгел, тематик яктан да отышлы. Әнвәр Бакиров, Алмаз Монасыйпов, Рәшит Гобәйдуллин, Фасил Әхмәт, Луиза Батыр-Болгари, Резедә Әхиярова, Илфат Дәүләтшин, Рәис Нәгыймов, Ганс Сәйфуллин, Фәрит Хатыйпов, Азат Хөсәенов, Зөфәр Хәйретдинов һәм башка бик күп композиторлар аның шигырьләренә берсеннән-берсе матуррак җырлар иҗат итте. Ш.Җиһангированың иҗат диапазонын шигъри лирика һәм җыр белән генә чикләп кую дөрес түгелдер. Ни өчен дигәндә, укучылар күңелен яулап алган повесть һәм хикәяләр, юмористик әсәрләр авторы да бит әле ул.

Шәмсия Җиһангированың радио-дагы эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Халык күңеленә юл тапкан берсен-нән-берсе кызыклы «Хәерле иртә», «Гомерләрдән моң һәм сүз кала», шагыйрьләр иҗатына багышланган «Шигырь уты йөрәгемдә», җырның барлыкка килү тарихын ачыклаучы «Остаханә» кебек тапшырулары аның иҗатчы буларак осталыгын, тоткан кыйбласын билгеләүче бер ачык дәлил.

"Исәннәргә һәйкәл кирәк түгел" дисәләр дә, әлеге мәсьәләне хәл итүче булсам, әллә кайчан Шәмсия апага һәйкәл куйган булыр идем. Ир-атларга куелган һәйкәлләр күп, ә хатын-кызларга, ни өчендер, һәйкәлләрне сирәк куялар.

Шәмсия Җиһангирова һәйкәле – хатын-кыз гүзәллеге, фидакарьлеге символы булып торырга тиеш. Мөслим кызлары нинди, дисәләр, мин: "Шәмсия апаныкы кебек чем-кара куе чәчле, тере күзле, тезелеп торган энҗеләрдәй ап-ак тешле, елмайганда, бит очлары чокыраеп, сине сихерли торган серле, ачык йөзле, туры сүзле, төп-төз гәүдәле," – дип әйтер идем. Скульптор, һәйкәлне ясаганда, һичшиксез, шул таләпләрдән чыгып эш итәргә тиеш. Беркем булдыра алмаганча итеп әнисен яратучы, зурлаучы шәфкать иясе, ихластан туган җирен сагынучы, җирсеп яшәүче милләттәшебез, бер үк вакытта кырыс та, гадел дә, таләпчән дә була белгән зат ул Шәмсия Җиһангирова. Аның һәйкәле янында олы яшьтәге апалар да, гашыйк кыз-кыркын да, егет-җилкенчәкләр дә җыела. Радиодан аның сүзләренә язылган җырлар яңгырый, кемдер кушылып җырлап ала, кайсыдыр шигырь укый. Аллы-гөлле күбәләкләр һәйкәл тирәсендәге хуш исле чәчәкләрне үбәләр, иркәлиләр. Якында гына кошлар сайраганы ишетелә, кечкенә генә куен дәфтәрен чыгарып, берәү күңелендәге хисләрен ак кәгазь битенә төшерә башлый. Матур хисләр уяна, яңа җыр туа, яшь талантлар туа... Минем күңелемә җыр килә.

**һәйкәл – истәлек! һәйкәл – тарих! һәйкәл – хәтер!** Күңелләрдә генә булса да, халкыбызның милли җанлы шәхесенә һәйкәл куйдык. Киләчәктә мондый һәйкәлләр калкып чыгар, күңелләрне сафландырып торыр алар! Афәрин! Шулай булсын!

***Тимур Салахов***

## "Эзләп-эзләп табалмас миннән гайре һичкем бу байлыкны..."

*Шагыйрем! кодсиятең булсын*
*синең күңлеңдә сер;*
*Дөньядан шагыйрь икәнеңне*
*яшер, дустым, яшер...*
*Г. Тукай*

Эзләп-эзләп табалмас миннән гайре һичкем бу байлыкны:

Рифмалап куям менә хәзер Җаек илә Баекны!

Таң калырлар кемсәләр бу Җаек берлән Баекка –

Көнләрләр, диеп: "Ник без түгел лаек бу байлыкка?!"

Бирел китим аңлатма: бу байлык синдә булсын чөн ни кирәк –

Туган вә үскән җирең Баек булу кирәк!

Дөрест, тырышсаң, башка охшашлык та табып була:

Аның – атасы, минем – бабамның аты ич Гарифулла!

Күп ятимлек, җәбер-золым, уй-фикерләр безем уртак...

Ни булыр йә булмас иде икәү бер заман тусак?!

Бу кадәресе безем акыл җитмәслек хәл менә! –

Кемнәрне кайчан бирмеш йә алмышны бер Ходам белә...

"Ник алар икәү?!." дип, йөрмәсенгә хәсетләр үпкәләп,

Биргән ул Тукайны миннән бер гасыр иртәрәк...

Бар җиһан таныган вә табынган хәлдә Тукаебыз бөегенә,

"Мөтәшагыйрь" димәсләр аңы бик зурлар мине дә.

Бу икәведә тоеп шагыйрәнә уртаклык (көн килсә!),

"Ходай рәхмәте лә бу!.." – дип сөрән сугар әле берәр кемсә.

...Бу заман һәркемгә мәгълүм Тукай кем дә! мин фәкыйрә кем, –

Мең охшашлык табарлар, ахырда килеп, көннән көн!

Ничек карыйлар бүген "Тукай..." дип Җаекка,

Шулай карарлар берзаман "ШәмсеҖиһан" дип Баекка!

Ә бүген?! Чабыш вә бүлештә "Тукайга кем лаек?"ны –

Мин яшим бары рифмалап Җаек илә Баекны...

Сизәм: шатрларга җитте бәгъзеләр үзенә мондый форсат – җай юкка...

Мин теләм бары: карыйм да илаһи Җиһан, Җаек... аннары Баекка!

***Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА***

# МИЛЛӘТЕМНЕҢ КОЯШЫ СИН, ТУКАЙ

## Гимназиядә республикакүләм "Бердәм Тукай дәресләре"



"Бердәм Тукай дәресләре" кысаларында гимназиябездә "Милләтемнең кояшы син, Тукай" әдәби-музыкаль кичәсе узды. Унынчы сыйныф укучыларыннан төзелгән инициатива төркеме көн дәвамында Габдулла Тукайның 130 еллыгына багышланган тематик чаралар оештырды. Проектның җитәкчеләре - унынчы сыйныф укучылары Бәдертдинова Динара, Әһлиуллина Язилә, Шәйгәрданова Регина.

## "Син Тукайны беләсеңме?" әдәби викторинасы



Гимназиябез бу көннәрдә Габдулла Тукай рухы белән яши. 5-6 нчы сыйныф укучылары "Син Тукайны беләсеңме?" дигән әдәби викторинада катнаштылар. Сораулар шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган иде. Укучылар Тукай иҗаты белән бик яхшы таныш һәм аның әсәрләрен яраталар. 5б сыйныфы укучылары Шәмсетдинов Айзат һәм Хәбибуллина Лиана, 6в сыйныфы укучысы Бәдертдинова Айсылу Тукай иҗаты һәм тормышы буенча үткәрелгән викторина җиңүчеләре дип табылды.

## Гимназиядә “Шәфкатьлелек акциясе”



Гимназия фойесында барган күргәзмә-сату рәтләрен күргәч, ирексездән, Габдулла Тукайның “Иртә белән кайнамакта бу базар, кайда бакма, шунда тулган сәүдәгәр” дигән юллары телгә килә. Шәфкатьлелек акциясе кысаларында узган чарада башлангыч сыйныф укучылары сәүдә итте, алар базар мөнәсәбәтләре нигезләрен гамәли үзләштерделәр, табышны изге максатларда файдаланырга өйрәнделәр.

## "Тукай безнең күңелләрдә" костюмлы тамашасы



Гимназия актлар залында башлангыч сыйныф укучылары өчен "Тукай безнең күңелләрдә" дип аталган бердәм Тукай дәресләре үтте. Балалар бөек шагыйребезнең шигырьләрен яттан сөйләделәр, костюмлы тамаша да оештырдылар.

## "Ирекле микрофон" бәйгесе җиңүчеләре



Гимназия фойесында оештырылган "Ирекле микрофон" дип аталган чарада көн дәвамында укучылар, укытучылар өчен Габдулла Тукай шигырьләрен микрофонга сөйләү мөмкинлеге тудырылды. Барлыгы 92 укучы чыгыш ясады. Иң актив укучылар 2а сыйныфында укый. Сәйфуллин Раушан, Ишинбаева Камилә, Авзалова Нәргизә, Ханнанова Адилә – иң оста сөйләүчеләр булды. 7б сыйныфы укучысы Филлипова Оля, 8б сыйныфы укучысы Ләйсән Мәгъданова “Су анасы” поэмасын рус телендә башкардылар. Инглиз телендә Г.Тукайның “Туган авыл” шигырен сөйләп, 9а сыйныфы укучысы Алсу Муллагалиева үз яшьтәшләре арасында җиңүче дип табылды.

## Йөрәкләрдә син, Тукай



5-10 нчы сыйныф укучылары өчен “Йөрәкләрдә син, Тукай” әдәби-музыкаль композициясе оештырылды. Кичәдә Г.Тукай шигырьләре аның сүзләренә язылган җырлар белән үрелеп барды. Кичәдә С.Сәйдәшевның “Тукай маршы” яңгырады, укучылар “Туган тел” җырын күмәк башкардылар.

## Тукайга ияреп иҗат итәбез: “XXI гасыр Шүрәлесе белән үткән бер

Төшенделәр эшнең асылына шүрәлеләр,
Хәзер инде берсе көлми, шүрләделәр.

Һич ярамый бу урманда озак тору,
Тиз арада кирәк булыр моннан таю.

Озын-озак юлга бик тиз җыендылар,
Шүркә, Шүрәлинә, башка шүрәлеләр.

Шул көннән соң башка очрамады,
Һичбер затка мондый җен-пәриләр.

***Әмир Дәүләтшин, 1б***

Шүрәле ыңгырашып утырганда, каяндыр бер бик сылу кыз килеп чыккан. Кыз, аны бик кызганып, кулын бүрәнә ярыгыннан алырга булышкан. Кайчандыр сихерләнгән Шүрәле тәүбәгә килә һәм матур егеткә әверелә. Гаилә корып, матур итеп яши башлыйлар.

***Ситдиков Алмаз, 4а***

Шүрәле Былтыр яшәгән авылга килеп чыккан. Ул Былтыр белән утын кисәргә өйрәнгән: бергәләп утынны ярып, өеп тә куйганнар. Шүрәле бу утын белән ни эшләүләре турында кызыксынган. Ә Былтыр мунча ягып җибәргән. Хуш исле себеркеләр белән чабынгач, Шүрәленең начарлык эшли торган гадәтләре онытылган. Шулай итеп Шүрәле башка урман Шүрәлеләрен дә мунча керергә өйрәткән. Хәзер Былтыр утынга барган саен, Шүрәлеләр аны хуш исле себерке белән мунча кертәләр, мәтрүшкәле, җиләкле чәй белән сыйлыйлар, ди.

Әлеге урман безнең Мөслим якларында, дусларым. Ямьле җәйләр җиткәч, сезгә дә Шүрәлеләр мунчасында кунак булырга мөмкинлек бар.

***Шәһрәт Мирзаморатов, 4а***





***Композицияләр күргәзмәсе***



## Й Ө Р Ә К Л Ә Р Д Ә   С И Н ,   Т У К А Й

### 10 НЧЫ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ТУКАЙНЫ “АЧА”



Габдулла Тукай

**Шәйгәрданова Регина:**

Минем өчен Г.Тукай – милләт язмышын кайгыртучы кеше. Ул милләтемә – татар милләтенә булган мәхәббәтне, кадерне арттыра. Аның белән бергә мин үзем дә кайгырам, борчылам, аның белән бергә янам. Тукай - бөек ул, хәзинә ул.

**Илнур Шәймөхәммәтов:**

Безне гаиләдә балачактан ук Тукай шигырьләре, әкиятләре белән тәрбия иттеләр. Бүген Тукай әсәрләре безне киләчәк тормышка әзерли. Тукай иҗаты минем гомерлек юлдашым булыр, дип саныйм.

**Динара Зарипова:**

Балалар бакчасыннан ук Габдулла Тукай иҗаты белән таныш идем. Мәктәп елларында мин аны бөтенләй башка яктан ача бардым. Быел исә мин аны яңа милли поэзиягә, заманча татар әдәби теленә нигез салучы буларак өйрәндем. Габдулла Тукай – шагыйрь генә түгел, халкыбызның теле дә, моңы да, рухы да ул. Тукай иҗаты – могҗизалы иҗат.

**Нурислам Сәлимгәрәев:**

Гасырлар узгач та, якты исеме онытылмаган шәхесләр күп булмый. Иҗтимагый идеаллар кайсы якка үзгәрсә дә, милләтенә чын күңелдән бирелгән шәхесләр онытылырга тиеш түгел, минемчә. Габдулла Тукай – нәкъ менә шундый шәхесләрнең иң күренеклесе. Аның талант дәрәҗәсен хәтта кузаллау да кыен. Иҗатына тормыш материалы үзе яшәгән чордан, көндәлек вакыйгалардан алынган. Габдулла Тукай халык рухы белән иҗат иткән, ул үз укучыларының җанында, кан тамырларында яши.



**Язилә Әһлиуллина:**

Габдулла Тукай – милләтебезнең йөзек кашы. Тукай иҗаты – могҗизага тиң иҗат. Габдулла Тукай – халык күңелендә мәңге сүнмәс учак кабызган бөек зат. Тукайны өйрәнергә, белергә һәм яратырга кирәк. Шулай гына аның әдәби байлыклары бездән соң киләчәк буыннарга сакланачак.

**Руслан Петров:**

Габдулла Тукай минем өчен беренче укытучым булып тора. Мин “Су анасы”, “Шүрәле”, “Кәҗә белән Сарык” әкиятләре аша тирә-юньне, дөньяны аңларга өйрәндем. “Эшкә өндәү”, “Кызыклы шәкерт”, “Сабыйга” шигырьләре миндә җаваплылык хисе, ихтыяр көче, тырышлык, максатчанлык тәрбияләргә булыштылар.

**Зәйнәп Хөснетдинова:**

Тукайны укыганда, халыкның рухи дөньясына төшенәсең. Аның язганнары дулкынландыра, йөрәк тибешен тизләтә, милләт гаме белән яшәргә рухландыра. Мин апаема һәр көнне кич белән китаплар укыйм. Сизеп торам: сеңлемә дә Г.Тукай шигырьләре, әкиятләре бик ошый.

## Т У К А Й Г А   Ә Й Т Е Р   С Ү З Е М . . .



### Тукайлы булу – үзе бәхет

Әгәр Тукай исән булса, мин аның янына барып, мавыктыргыч әкиятләре, үлемсез шигырьләре өчен рәхмәт әйтер идем. Чыннан да, аның шигырьләре бар кешенең тормышын яктырта, сагыш-хәсрәтләрне җиңеләйтә, бәйрәмнәребезне бизи.

Тукайның бөеклеген яшь чагында ук халык бәяләгән, кадерен белгән, аны саклаган. Тукаебыз булу - милләтебез өчен зур бәхет ул. Аның көчле рухлы булуы, авырлыкларга бирешмәве яшәргә көч бирә, киләчәккә өмет уята. Бүген ул арабызда булмаса да, аны бар халык белә, чөнки ул иң югарыда балкып тора.

***Харисова Инзилә, 6в***

### Рәхмәт сиңа, бөек Тукай!

Мин Габдулла Тукай шигырьләрен укырга бик яратам. Әкиятләрен яттан сөйлим. Укыган саен, үзем өчен яңалыклар ачам. Тукае булган татар милләтенең бер вәкиле булуым белән чиксез горурланам.

***Кашапова Азилә, 6в***

### Тукай – “Рекордлар китабы”нда

...Әгәр Тукай исән булса, татар дөньясында гына түгел, бөтендөнья әдәбиятында иң югары дәрәҗәгә ирешкән шагыйрь булыр иде. “Рекордлар китабы”ның иң беренче битендә торыр иде.

***Рәхмәтуллина Адилә, 6в***

### Тукай белән чәй өстәле артында...

Әгәр Тукай исән булса, мин аны үзебезгә кунакка чакырыр идем. Тәмле коймаклар пешереп, чәй өстәле янында әңгәмә корыр идек.

Аның белән бүгенге проблемалар турында сөйләшер идек. Балаларның төннәр буе интернетта утырулары, китап укырга яратмаулары турында сөйләп, бу хәлдән чыгу юллары турында киңәшләшер идем. Бүгенге көндә дә кызыксынып, мавыгып укырдай әсәрләр язуының серен белэсем килә.

Тукай белән очрашып сөйләшү миңа зур бәхет булыр иде. Мин бу хакта иптәшләремә дә сөйләр идем.

***Фәттахова Зөлфия, 7б***

***Мәгълүматларны З.Н. Шәнгәрәева туплады.***

## ӘДӘБИ СӘХИФӘ




### БАЛДАЙ ТАТЛЫ СҮЗЛӘР

*Җирдәге һәрбер баланың*
*Беренче сүзе – "ӘНИ".*
*Балдай татлы, җанга рәхәт,*
*Иң назлы сүз ул – "ӘНИ"!*

*Иртән торып кадерлемә:*
*"Хәерле иртә!" – диям.*
*Төнлә йокларга ятканда:*
*"Хәерле төннәр!" – диям.*

*Балдай татлы сүзләрне*
*Күбрәк әйтсен телебез.*
*Җанга якын әниләрне*
*Бал-майда яшәтербез.*

***Зөһрә Закирова,***
***5 нче б сыйныф укучысы***

### ТАТЛЫ СҮЗДӘН ҖАН ЭРИ

*Йомшак телле, тәмле сүзле*
*Кыз булу җаен беләм.*
*Матур, ягымлы сүзләрнең*
*Тылсымлы көчен тоям.*

*Тәмле телем белән җайлап,*
*Сихерлим әбиемне.*
*Татлы сүземне кызганмыйм -*
*Сөендерәм бабамны.*

*Әниемә – "әнкәем" дим,*
*Әтиемә – "әткәем".*
*"Гөлкәем" дим гөлләргә,*
*"Пескәем" дим песигә.*

*Яхшы сүздән эрегәннәрен*
*Күргәнегез бармы соң?*
*Йомшак сүзне кызганмагыз,*
*Телегез арымасын.*

***Лиана Хәбибуллина,***
***5 нче б сыйныф укучысы***

### ӘКИЯТЛӘР ТЫЛСЫМЫ

*Дәү әнием миңа сабый чакта*
*Сөйли иде әкият:*
*Гүзәл кызлар, Дию-пәри,*
*Су анасы утыра чәч тарап...*
*Кәҗә белән Сарык сәфәр чыккан,*
*Кемнәр белми Камырбатырны?*
*Бүгенгәчә озата бара*
*Әкиятләр шомы, тылсымы.*

### ТУГАН ТЕЛЕМ

*Чиста итеп саф татарча сөйлим,*
*"Кем өйрәтте сине?" – дип сора.*
*Йомшак сүзле газиз әнкәм:*
*"Бәбкәм," - дип назлап тора.*
*Әтием дә, дусларым да*
*Саф татарча сөйләшә.*
*Туган телем - Тукай теле,*
*Гасырларда син яшә!*

***Диләрә Нуриева,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***

### ТУГАН АВЫЛЫМА

*Әби-бабай авыл өчен*
*Бик шәп урын сайлаган:*
*Уңда – урман, сулда – таулар,*
*Чишмәсе, инеше бар.*

*Туган авылым – Метрәй минем,*
*Чуерташлы су буе.*
*Йөрәкле Тау, Чишмә Башы,*
*Солтанай-Каран, Нади Кулы...*

*Мәтрүшкәле аланнарның*
*Мең чиргә дәвасы бар.*
*Тау бөтнеге, гөлбадранның*
*һәркемгә шифасы бар.*

*Тукай язганнан ким түгел*
*Бездә дә чыршы-нарат.*
*"Төпләрендә ятканым бар*
*Хәл җыеп күккә карап."*

*Җәй көннәре җыя халык*
*"Кура җиләк тә җир җиләк."*
*Кил әйдә, җыярсын син дә*
*"Күз ачып йомганчы бер чиләк."*

*Сандугачлы болыннарда*
*Күбәләкләр уйнышлар.*
*Туган якның гүзәллеген*
*Көйгә салып җырлыйлар.*

*Метрәемнең халкы данлы,*
*Тырыш, уңган, мактаулы.*
*Булсам иде туган якның*
*Мин дә бер сандугачы.*

***Язилә Әһлиуллина,***
***10 нчы сыйныф укучысы***

## ШИГЪРИ КҮЧТӘНӘЧ

### ҖУЕЛМАСЫН КҮҢЕЛЛӘРДӘН ТУКАЙ!

Язгы җилләр иркәләдеме сине,
Башкаеңнан сыйпадымы кояш нуры?
Куеныңда йөрттең ятимлекне,
Кыска булды синең гомер юлы.

Гасыр дәвамында иҗатыңа
Баш иябез, син бит – хөрмәтле.
Ятимлеккә түгел, бөек хезмәтеңә,
Һәйкәл куйды татар милләте.

Җир йөзендә синдәй үксезләр күп,
Битарафлык басты дөньяны...
Телен бозып: "Мама,"- дия,
Татар карчыгының оланы.

Милләтнең чын җанатары –
Тукай! Син бит яшәү өлгебез.
Туган телне сабый чактан
Өйрәнергә тиеш затлар без.

### ТУГАН ТЕЛЕМ

Тукай бабам иҗат иткән
Данлы татар илендә.
Гасырлык мирас калдырган
Гади туган телемдә.

Дәрәҗәсе данлы, теле йөгерек,
Татарлыгы белән ил бөек!
Туган телен белмәүченең,
Беләм төгәл: күңеле китек.

Туган телне – Тукай телен,
Алыштырмам чит телгә.
Казлар да каңгылдаша ич,
Үзләре белгән телдә.

Энҗе бөртегедәй кадерлим,
Әнкәм телен – татар телен.
Туган илемдә адашмам,
Нурлы булыр һәрбер көнем.

***Гимназияне тәмамлаган***
***Илназ Кашаповның Тукайга***
***багышланган шигъри тәлгәшләре***

ТЫЛСЫМ+
Апрель, 2016 нчы ел
**Мөслим гимназиясе укучылары газетасы**

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Муллагалиева Алсу
**Корреспондентлар:** Мәгъдәнова Ләйсән, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Хәбибуллин Руслан

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym

**Тираж:** 200 данә